**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Карашай-Саклау авыл җирлегенең Карашай-Саклау авылы торак пунктында
2023 елда үзара салым кертү турында

**2022 елның 17 ноябре** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Карашай-Саклау авыл җирлегенең Карашай-Саклау авылы торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. 2023 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Карашай-Саклау авыл җирлегенең Карашай-Саклау авылы торак пунктында I төркем инвалидларыннан, 90 яшьтән өлкәнрәк затлардан, көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш,мобилизованныйларнын гаилэ эгъзэлэренннэн тыш , яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

1) Карашай Саклау торак пунктында су җибәрү өчен янгын ранецлары, су өчен савытлар, трейлер һәм насос сатып алу;
2) Карашай Саклау торак пунктында МТЗ-82.1 тракторын карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу);
3) Карашай Саклау торак пунктында көнкүреш калдыкларын, чүп-чарны вакытлыча җыеп алу һәм чистарту (махсус техниканы арендалау, килешү буенча эшләрне һәм хезмәт күрсәтүләрне түләү) ;
4) призлар, азык-төлек җыелмалары алу; бәйрәмнәр үткәрү өчен туклануны оештыру (Авыл коне, инвалидлар көне, Өлкәннәр көне, юбилярлар, әфганчылар турнирын уздыру, авганец ветеранына мемориаль такта алу );
5) Карашай Саклау т. п. зираты өчен каты көнкүреш калдыклары өчен контейнерлар, мотобур, Триммер сатып алу;
6) Карашай Саклау торак пунктында җиләк-җимеш агачлары үсентеләрен сатып алу һәм утырту, агач утырту өчен махсус техниканы арендалау (килешү буенча эшләр өчен түләү);

3. Әлеге карарны Карашай-Саклау авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Сарман муниципаль районы
Карашай-Саклау авыл җирлеге башлыгы,
гражданнар җыенында рәислек итүче В.В.Хосниева